ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ с. Верхний Услон КАРАР ______________

«Югары Ослан районының 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 елларның планлы чорына бюджеты турында» 2017 елның 11 декабрендәге 28-308 номерлы карарын гамәлгә ашыру чаралары хакында

«Югары Ослан муниципаль районының 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 елларның планлы чорына бюджеты турында» Югары Ослан муниципаль районының 2017 елның 11 декабрендәге 28-308 номерлы карарның үтәлешен тәэмин итү максатларында Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2018 елның 1 гыйнварыннан 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 елларның планлы чорына Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетын кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторларына:

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр кертүне тәэмин итү, шулай ук аларны түләү бурычларын кыскарту чараларын күрергә;

квартал саен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән срокларга һәм рәвешләргә туры китереп, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетына керемнәрнең чиктән тыш күп булуы фаразларын тапшырырга;

квартал саен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетының керемнәр өлешендә үтәлеше турында, Татарстан Республикасы Финанс Министрлыгы билгеләгән срокларда бюджетның фактта үтәлеше сәбәпләрен күрсәтеп, аналитик материаллар тапшырырга;

3. Югары Ослан муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторына квартал саен Татарстан Республикасы Финанс Министрлыгы билгеләгән сроклар һәм формалар нигезендә Югары Ослан муниципаль районы бюджеты кытлыгын эчке һәм тышкы финанслау чыганакларын ай саен җәлеп итү һәм каплау фаразларын тәкъдим итәргә тиеш.

4. Билгеләргә:

2018 елның 1 гыйнварына файдаланылмаган бюджетара трансфертларның калган өлеше Югары Ослан муниципаль районы бюджетына, максатчан билгеләнеше булган башка бюджетара трансфертлар рәвешендә, авыл җирлекләре бюджетларына бирелгән бюджетара трансфертларның калган өлеше Югары Ослан муниципаль районы бюджетына кайтарылырга тиеш;

2017 елда бирелгән һәм максатчан билгеләнешле бюджетара трансфертларның калган өлешләренә ихтыяҗ булу турында карарлар күрсәтелгән калдыктан артмаган күләмдә кабул ителә:

әгәр 2018 елда Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетыннан җирлек бюджетына файдаланылмаган бюджетара трансфертлар биргәндә элек билгеләнгән максатларга бюджетара трансфертлар бирү каралмаган һәм җирлек бюджеты акчаларын алучы, финанс белән тәэмин итү чыганагы бюджетара трансфертларның калган өлешен тәшкил иткән бюджет йөкләмәләре үтәлмәгән булса.

5. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты бүлекләренә:

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының муниципаль программаларын "2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Югары Ослан муниципаль районы бюджеты турында" 2017 елның 11 декабрендәге 28-308 номерлы карарына туры китерүне бюджет законнары белән билгеләнгән срокларда тәэмин итәргә..

6. Билгеләргә:

Югары Ослан муниципаль районының муниципаль милеген хосусыйлаштыру буенча конкурста, аукционда катнашучылар тарафыннан кертелә торган акчалар, Югары Ослан муниципаль районы исеменнән төзелгән муниципаль контрактларны үтәүне тәэмин итү сыйфатында Югары Ослан муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алуларда катнашучылар тарафыннан кертелә торган акчалар, Югары Ослан муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алуларда катнашучылар тарафыннан сатуларда катнашу өчен гариза бирү сыйфатында кертелә торган Югары Ослан муниципаль районы учреждениеләренең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык Департаментының территориаль бүлегендә алар тарафыннан ачылган шәхси счетларында исәпкә алына;

Югары Ослан муниципаль районы бюджеты акчаларын алучылар Югары Ослан муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән түләнергә тиешле товарларны китерү, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү турында шартнамәләр төзегәндә, билгеләнгән тәртиптә аларга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә аванс түләүләрен күздә тотарга хокуклы:

а) шартнамә (контракт) суммасының 100 процентына кадәр, ләкин бюджет йөкләмәләренең лимитларыннан артык булмаган - шартнамәләр (контрактлар) буенча басмаларга язылу һәм аларны сатып алу, элемтә, кабель һәм спутник телевидениесе хезмәтләрен күрсәтү, ягулык-майлау материаллары, транспорт чаралары, юлламалар, авиация, тимер юл, шәһәр һәм шәһәр яны транспортында йөрү өчен билетлар, ашыгыч билгеләнгән медикаментлар (кешенең гомеренә куркыныч янаган очракта кичектергесез медицина ярдәме күрсәтү өчен таләп ителә торган медикаментлар) сатып алу, квалификация күтәрү курсларында укыту, яңадан һөнәри әзерлек узу, фәнни, методик, фәнни-гамәли һәм башка конференцияләрдә катнашу, проект документларына һәм инженерлык тикшеренүләренә дәүләт экспертизасы уздыру, капиталь төзелеш, реконструкцияләү яисә техник яктан яңадан кораллану

объектларының смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерүне уздыру, шартнамәләр буенча транспорт чаралары хуҗаларының граждан җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү, фәнни, мәдәни, экскурсия һәм спорт чараларын уздыруга шартнамәләр, янгын сүндерү буенча чаралар үткәрү турында шартнамәләр (муниципаль контрактлар) буенча хезмәт күрсәтүләр өчен мәгълүмат белән тәэмин итү, түләү;

б) Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, шартнамә (контракт) суммасының 30 процентына кадәр, ләкин бюджет йөкләмәләренең лимитларыннан артык булмаган - башка шартнамәләр (контрактлар) буенча;

Югары Ослан муниципаль районы бюджетыннан юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) (алга таба - юридик затлар), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга - товар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү, Россия Федерациясе бюджет кодексы нигезләмәләрен исәпкә алып, 2018 елда гамәлгә ашырыла.

7. Югары Ослан муниципаль районының Финанс-бюджет Палатасына:

2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетының җыелма бюджет язмасында билгеләнгән күләмдә бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары турында бюджет чараларын баш күрсәтмә бирүчеләргә җиткерергә;

8. Кулланыу муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар сатып алуга, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә бәйле булган субсидияләрне җирлекләргә күчерү сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән контракт (килешү) булганда гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

контрактта (шартнамәдә) билгеләнгән күләмдә аванс өчен түләүгә;

Эшләрне башкаруны, хезмәтләр күрсәтүне, товар китерүне раслый торган документлар булганда контракт (шартнамә) буенча куелган товарның башкарылган эшләре өчен түләүгә.

9. Югары Ослан муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләргә:

аларга кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм расланган бюджет язмалары күрсәткечләре нигезендә Югары Ослан муниципаль районы бюджеты акчаларын алучылар арасында бюджет йөкләмәләре лимитларын бүлергә.

10. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

11. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хәкимҗанов

Әзерләде һәм
бастырды
Ю.В. Козина 4 нөсхәдә.